Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Советы

Надеждино авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

4 апрель, 2025 ел № 1

«2024 елгы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатларында «2024 елгы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге бюджетын үтәү турында» Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге территориясендә җәмәгать фикер алышуын һәм гавами тыңлауларны оештыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 66 номерлы (2017 елның 13 декабрендәге 79 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 93 номерлы, 2019 елның 20 сентябрендәге 131 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 55 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 62 номерлы карарлар редакциясендә) карары белән карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге бюджетының 2024 елгы үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының (алга таба - Совет карары проекты) карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты;

2.2. гавами тыңлаулар уздыру датасы һәм вакыты - 2025 елның 30 апреле, 14.00 сәгать;

2.3. гавами тыңлаулар үткәрү урыны - Надеждино авылы, Школьная урамы, 4 йорт, Надеждино авыл мәдәният йортының тамаша залы;

2.4. Надеждино авылы, Школьная урамы, 4 нче йорт адресы буенча фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, Совет карары проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырылырга мөмкин.

3. Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Советның карар проектын Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) 2025 елның 18 апреленнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.2. Советның билгеләнгән тәртип һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда карары проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.3. гавами тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар бәяләмәсен, шулай ук Советның эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов